| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУСЛЮМОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.09.2025 Мөслим № 453

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Сәүдәләрдә җир кишәрлеген арендага, милекне электрон рәвештә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында» 2019 елның 28 ноябрендәге 734 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Пространство белешмәләренең милли системасы» бердәм цифрлы платформасы федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы карары белән, Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының 2019 елның 28 декабрендәге 734 номерлы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы күрсәтмәсе белән расланган территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 бүлекнең 3.3 пунктындагы 3.3.3.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.2. Регламентның 3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында, шул исәптән, пространство күрсәткечләреннән файдаланып, пространстволы мәгълүматның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»

- 3 бүлекнең 3.5 пунктындагы 3.5.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.5. Регламентның 3.5.2, 3.5.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.2, 3.5.4 бүлекләрендә күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында, шул исәптән, пространстволы мәгълүматлардан файдаланып, милли киңлек мәгълүматларының функцияләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**